КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 июнь г.Казань № 512

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нче; 2017 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 797 нче; 2018 ел, 6 апрель, 211 нче; 2018 ел, 31 июль, 623 нче; 2018 ел, 3 декабрь, 1076 нчы; 2019 ел, 12 март, 178 нче; 2019 ел, 28 май, 446 нчы, 2019 ел, 12 ноябрь, 1033 нче, 2020 ел, 06 апрель, 256 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2022 елларга» сүзләрен "2014 – 2023 елларга" сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2022 елларга» сүзләрен "2014 – 2023 елларга" сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт

программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 – 2022 елларга» сүзләрен "2014 – 2023 елларга" сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа исеме | 2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитеты |
| Программаның максаты | Туризм инфраструктурасын, шулай ук мәдәни-тарихи, табигый потенциалны, республиканың вакыйгалар туризмы потенциалын һәм кунакчыллык индустриясен үстерү нигезендә Россия һәм халыкара туристлык базарларында Татарстан Республикасы туристлык комплексының конкурентлылыкка сәләтен арттыру |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасының уңай туристик имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләре күләмен һәм төрлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасының Туристлык-рекреация комплексын үстерү.<br>3. Конкурентлыкка сәләтле туристлык продуктын формалаштыру һәм аны перспективалы туристик базарларда таныту.<br>4. Республика туристлык продуктының сыйфатын, гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, туризм индустриясе объектларында туристларга хезмәт күрсәткәндә кунакчыллык дәрәҗәсен арттыру.<br>5. Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2014 – 2023 еллар:<br>I этап: 2014 – 2017 еллар;<br>II этап: 2018 – 2023 еллар |
| Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 3 055,4 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 394,8 млн.сум:<br>2014 ел – 20,0 млн. сум;<br>2015 ел – 97,3 млн. сум;<br>2016 ел – 87,1 млн. сум; |

| | |
|---|---|
| | 2017 ел – 231,5 млн. сум;<br>2018 ел – 99,8 млн. сум;<br>2019 ел – 120,1 млн. сум;<br>2020 ел – 170,5 млн. сум;<br>2021 ел – 274,2 млн. сум;<br>2022 ел – 198,2 млн. сум;<br>2023 ел – 96,1 млн. сум;<br>федераль бюджет акчасы исәбеннән– 523,2 млн. сум:<br>2017 ел – 41,8 млн. сум;<br>2020 ел – 96,3 млн. сум;<br>2021 ел – 244,1 млн. сум;<br>2022 ел – 141,0 млн. сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы исәбеннән – 5,1 млн. сум:<br>2014 ел – 3,3 млн. сум;<br>2015 ел – 1,8 млн. сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акча исәбеннән – 1 132,3 млн. сум:<br>2015 ел – 250,0 млн. сум;<br>2016 ел – 779,2 млн. сум;<br>2017 ел – 103,1 млн. сум.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы терииториясендә туристлык-рекреация һәм автотуристлык кластерларын төзү күздә тотыла.<br>Чаралар булдырыла торган кластерларны «Россия Федерациясендә эчке һәм чит ил туризмын үстерү (2011 – 2022 еллар)» федераль максатчан программасына кертү очрагында тормышка ашырылачак.<br>Программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:<br>Татарстан Республикасына эчке һәм керә торган туристлар агымын арттыру:<br>2014 елда – 2 530,7 мең кеше;<br>2015 ел – 2 750,4 мең кеше; |

| | |
|---|---|
| соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2016 елда – 2 955,5 мең кеше;<br>2017 елда – 3 181,0 мең кеше;<br>2018 елда – 3 423,8 мең кеше;<br>2019 елда – 3 627,8 мең кеше;<br>2020 елда – 3 845,5 мең кеше;<br>2021 елда – 4 076,2 мең кеше;<br>2022 елда – 4 320,7 мең кеше;<br>2023 елда – 4 579,9 мең кеше;<br>халыкка күрсәтелгән түләүле турист хезмәтләре күләме:<br>2014 ел – 10 030,9 млн. сум;<br>2015 ел – 11 310,5 млн. сум;<br>2016 ел – 11 696,3 млн. сум;<br>2017 ел – 13 566,5 млн. сум;<br>2018 ел – 14 258,4 млн. сум;<br>2019 ел – 14 500,0 млн. сум;<br>2020 ел – 14 850,0 млн. сум;<br>2021 ел – 15 100,0 млн. сум:<br>2022 ел – 15 270,0 млн. сум;<br>2023 ел – 15 300,0 млн. сум;<br>туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерлекле белгечләр саны:<br>2014 ел – 400 кеше;<br>2015 ел – 425 кеше;<br>2016 ел – 450 кеше;<br>2017 ел – 475 кеше;<br>2018 ел – 480 кеше;<br>2019 ел – 485 кеше;<br>2020 ел – 490 кеше;<br>2021 ел – 495 кеше;<br>2022 ел – 500 кеше;<br>2023 ел – 500 кеше»; |

Программаның II бүлегендәге кырык бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыру вакытлары – 2014 – 2023 еллар. Программа ике этапта тормышка ашырылачак. Беренче этап – 2014 – 2017 еллар, икенче этап – 2018 – 2023 еллар. Төп максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук финанслау күләмнәре Программа чаралары кисемендә Программага кушымтада китерелгән.»;

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 3 055,4 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 394,8 млн.сум:

2014 ел – 20,0 млн. сум;
2015 ел – 97,3 млн. сум;
2016 ел – 87,1 млн. сум;
2017 ел – 231,5 млн. сум;
2018 ел – 99,8 млн. сум;
2019 ел – 120,1 млн. сум;
2020 ел – 170,5 млн. сум;
2021 ел – 274,2 млн. сум;
2022 ел – 198,2 млн. сум;
2023 ел – 96,1 млн. сум;
федераль бюджет акчасы – 523,2 млн. сум:
2017 ел – 41,8 млн. сум;
2020 ел – 96,3 млн. сум;
2021 ел – 244,1 млн. сум;
2022 ел – 141,0 млн. сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль бюджетлар акчасы – 5,1 млн. сум:
2014 ел – 3,3 млн. сум;
2015 ел – 1,8 млн. сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш акча – 1 132,3 млн. сум:
2015 ел – 250,0 млн. сум;
2016 ел – 779,2 млн. сум;
2017 ел – 103,1 млн. сум.»;

IV бүлекнең алтынчы һәм унынчы абзацларында «Татарстан Республикасы дәүләт программалары нәтиҗәләлеге"сүзләреннән соң «ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

Программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру 2023 ел ахырына Татарстан Республикасы туристлык базарының конкурентлыкка сәләтлелеген арттырырга, шулай ук Россия һәм чит ил гражданнарының сыйфатлы туристлык хезмәтләренә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының туристлык-рекреация комплексы сизелерлек үсеш алачак, туристик хезмәтләрнең сыйфатын арттырачак, шулай ук дөнья һәм эчке базарларда туристик продуктны алга этәрү бурычы хәл ителәчәк.

2023 елда Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә эчке һәм чит ил туристлары агымнары күләме 4 579,9 мең кеше тәшкил итәр дип көтелә; туризм өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү күләме – 15 300,0 млн.сум; Программа гамәлдә булган бөтен чорда туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерләнгән белгечләр саны – 500

кеше.

Программаны гамәлгә ашыру чорында Татарстан Республикасының туризм һәм туризм өлкәсендә эш урыннары саны 20 мең кеше тәшкил итәчәк.

Программада каралган чаралар Татарстан Республикасында туризм үсешендә уңай тенденцияләрне беркетергә мөмкинлек бирәчәк, бу исә яңа туристик инфраструктура булдыруга һәм булган инфраструктураны яңартуга, һәм, нәтиҗәдә, Татарстан Республикасы территориясендә конкурентлыкка сәләтле заманча туристик тармак булдыруга ярдәм итәчәк. Якынча бәяләүләргә караганда, программаны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән чараларны үтәүне исәпкә алып, аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң, югары нәтиҗәле туристик-рекреацион инфраструктура булдырырга мөмкинлек бирәчәк, бу исә «Туризм» статьясы буенча Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше үсешенең югары динамикасын тәэмин итәчәк.

Программаның бурычларын хәл итү республика һәм тулаем Россия Федерациясе икътисадын тотрыклы үстерү өчен мультипликатив эффект бирәчәк, әмма бу бурычлар бары тик дәүләт һәм муниципаль берәмлекләр һәм шәхси инвесторлар ярдәме белән генә тормышка ашырылырга мөмкин.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин